**Татарстан Республикасы**
**Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

«26» май 2025 ел № 120

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 июлендәге 70 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Яңа Шашы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать тәртибен саклау буенча ирекле халык дружиналары турында Нигезләмәне раслау хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының 2015 елның 16 гыйнварындагы №4-ЗРТ «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» Законы, Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 31 гыйнварындагы №02-08-02-2025/Прдп42-25 номерлы протесты нигезендә, Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 июлендәге 70 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Яңа Шашы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать тәртибен саклау буенча ирекле халык дружиналары турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. Карар преамбуласында** «2005 елның 1 ноябрендәге №107-ЗРТ 'Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнар катнашуы турында'» сүзләрен «2015 елның 16 гыйнварындагы №4-ЗРТ «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» сүзләренә алыштырырга.

**1.2. Нигезләмәнең 2 нче статьясында** «2005 елның 1 ноябрендәге №107-ЗРТ Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнар катнашуы турында» сүзләрен «2015 елның 16 гыйнварындагы №4-ЗРТ «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» сүзләренә алмаштырырга.

**1.3. Нигезләмәнең 10 статьясының 2 пунктында** «Россия ЭЭМның "Биектау" муниципаль районы буенча "Әтнә" полиция бүлеге» сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.4. Нигезләмәнең 13 статьясының 2 пунктының 2, 3 подпунктларында** «Россия ЭЭМның "Биектау" муниципаль районы буенча "Әтнә" полиция бүлеге» сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.5. Нигезләмәнең 14 статьясының 4 пунктында** «ОП» сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.6. Нигезләмәнең 18 статьясының 4 пунктында** “Биектау” Россия ЭЭМ (“Әтнә”) ПБ” сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.7. Нигезләмәнең 23 статьясының 1 пунктында** “Биектау” Россия ЭЭМ (“Әтнә”) полиция бүлекчәсе” сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.8. Нигезләмәнең 23 статьясының 5 пунктында** «Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда халыкның катнашуы турында» сүзләрен «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы: Сабирҗанов М.С..